КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 февраль г.Казань № 183

«Шомбыт» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) тыюлыгын бетерү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Шомбыт» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) тыюлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә Кама алдының экологик-географик зонасында аучылык объектларына кертелгән хайваннар дөньясы объектларының, ә атап әйткәндә елга кондызы, тиен, көртлек популяциясен һәм аларның яшәү тирәлеген саклау, шулай ук аның чикләрендә аучылык хуҗалыгы булдыру буенча үз функциясен үтәүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының «Шомбыт» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) тыюлыгы бетерү һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында аучылык хуҗалыгы булдыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бетерелә торган «Шомбыт» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) тыюлыгы территориясендә аучылык ресурсларының тотрыклы яшәвен һәм алардан файдалануны, аларның биологик төрлелеген саклауны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына өч ай вакыт эчендә аучылык хуҗалыгы килешүен төзү хокукына аукцион уздыру юлы белән аучылык хуҗалыгын төзү буенча кирәкле чаралар үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мишә» һәм «Шомбыт» дәүләт табигать аучылык тыюлыклары турында» 2004 ел, 29 гыйнвар, 41 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 737 нче; 2018 ел, 21 май, 382 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче, 2019 ел, 27 март,

226 нчы, 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче, 2022 ел, 22 февраль, 152 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мишә» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоологик (аучылык) тыюлыгы турында»;

2 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрын раслау һәм махсус саклана торган табигать территорияләре мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, 520 нче карары белән (Татарстан Республикасы Мини-стрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2011 ел, 26 июль, 604 нче; 2011 ел, 8 август, 641 нче; 2012 ел, 17 июль, 600 нче; 2013 ел, 27 март, 208 нче; 2013 ел, 1 июнь, 374 нче; 2013 ел, 6 июнь, 390 нчы; 2014 ел, 20 май, 335 нче; 2014 ел, 11 июнь, 399 нчы; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 904 нче; 2016 ел, 11 июль, 475 нче; 2016 ел, 21 июль, 493 нче; 2017 ел, 31 гыйнвар, 42 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 744 нче; 2018 ел, 12 февраль, 76 нчы; 2018 ел, 21 май, 380 нче; 2019 ел, 26 март, 221 нче; 2019 ел, 28 май, 445 нче; 2020 ел, 5 февраль, 77 нче; 2020 ел, 6 октябрь, 909 нчы, 2020 ел, 04 ноябрь, 994 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында махсус саклана торган табигать территорияләре дәүләт реестрына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Аңлату язмасы» бүлегендә:

җиденче абзацта «190 махсус сакланылучы табигать территориясе» сүзләрен «191 махсус сакланылучы табигать территориясе» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «39» саннарын «38» саннарына алмаштырырга;


ундүртенче абзацта «464,689» һәм «6,8» саннарын тиешенчә «464,699» һәм «6,9» саннарына алмаштырырга;

унҗиденче абзацта «6» санын «5» санына алмаштырырга;

«Балык Бистәсе муниципаль районы» бүлегендә:

Балык Бистәсе муниципаль районының карта-схемасын һәм аңа искәрмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балык Бистәсе муниципаль районы




[124] – Берсутские пихтарники
[126] – Мешинский
[136] – река Ошняк
[139] – река Бетька
[140] – река Суша
[141] – река Шумбут
[142] – Лесные культуры лиственницы 1906 года
[200] – Нерестилище стерляди»;

«Шомбыт [143]» бүлекчәсен үз көчен югалткан дип танырга;

күрсәтелгән Татарстан Республикасында махсус сакланылучы табигать территорияләре дәүләт реестрына 2 нче кушымтада «Шомбыт [143]» бүлекчәсен үз көчен югалткан дип танырга.

5. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан АССР Министрлар Советының «Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы Дәүләт аучылык инспекциясенең хуҗалык-финанс эшчәнлеге йомгаклары турында» 1963 елның 25 июнендәге 356 номерлы карары;

Татарстан АССР Министрлар Советының 1973 елның 09 октябрендәге 837-б номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 28 декабрь, 2239-б номерлы боерыгы.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин